# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**“Татарстан Республикасының административ-территориаль төзелеше турында” Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2010 елның 23 декабрендә
кабул ителде

**1 статья**

“Татарстан Республикасының административ-территориаль төзелеше турында” 2005 елның 7 декабрендәге 116-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 12 (I өлеш); 2007, № 12 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 4 һәм 5 статьяларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“4 статья. **Татарстан Республикасының административ-территориаль берәмлекләре исемнәренең теле һәм аларны нормалаштыру**

1. Татарстан Республикасының административ-территориаль берәмлекләренең исемнәрен язу телләр турындагы законнар нигезендә татар һәм рус телләрендә башкарыла.

2. Татарстан Республикасының административ-территориаль берәмлекләре исемнәрен нормалаштыру, җирле халык мәнфәгатьләрен исәпкә алып, Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасының административ-территориаль берәмлекләре исемнәренең татар, рус телләрендә һәм башка телләрдә куллану кагыйдәләре һәм традицияләре нигезендә гамәлгә ашырыла.

5 статья. **Административ-территориаль берәмлекләргә исем бирү һәм аларның исемнәрен үзгәртү**

1. Административ-территориаль берәмлекләргә исем бирү һәм аларның исемнәрен үзгәртү турындагы тәкъдимнәрне Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан карау һәм аларны географик объектларның исемнәре өлкәсендә вәкаләтле федераль башкарма хакимият органына һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенә җибәрү турында карарлар кабул итү географик объектларның исемнәре турындагы законнар һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан расланган нигезләмә нигезендә гамәлгә ашырыла.

2. Почта-телеграф учреждениеләре яисә тимер юл станцияләре булган административ-территориаль берәмлекләрнең исемнәрен үзгәртү турында үтенечнамәләр бирелгәндә, үтенечнамәләр кертүче органнар бу административ-территориаль берәмлекләрнең исемнәрен үзгәртүне тиешле элемтә һәм тимер юллар идарәсе органнары белән килештерәләр.";

2) 10 статьяның сигезенче абзацында "башкарма хакимиятнең вәкаләтле федераль органына" сүзләрен "географик объектларның исемнәре өлкәсендә вәкаләтле федераль башкарма хакимият органына" сүзләренә алмаштырырга;

3) 11 статьяның алтынчы абзацын үз көчен югалткан дип танырга;

4) 12 статьяның дүртенче абзацын үз көчен югалткан дип танырга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2010 елның 31 декабре
№ 133-ТРЗ